ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт: http://ojm.tatarstan.ru

Приказ | Казан шәһәре | Боерык

25.09.2024 | № 257- од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 13 ноябрендәге 315-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын федераль законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 13 ноябрендәге 315-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә кертелә торган теркәлгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Р.Г. Шәрәфетдиновка йөкләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының 2024
елның 25 сентябрендәге 257-од
номерлы боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 13 ноябрендәге 315-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә кертелә торган үзгәрешләр

2 пунктта:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 127-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче гражданның, шәхси эшмәкәрнең банкротлык процедурасын тәмамлау – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә түләү бурычын үтәүдән азат ителгән түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч өлешендә;»;

3 нче пунктчаны үз көчен югалткан дип таныргa;

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки ярлыкау турындагы актларны куллану яисә суд тарафыннан бюджет керемнәре администраторы ТР бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта торган карар кабул итү, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә;»;

6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 229-ФЗ номерлы Федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда , суд приставы-башкаручының башкарма эшне тәмамлау турында карар чыгаруы, әгәр күләме бурычлыга карата банкротлык турында эш кузгату өчен бөлгенлек (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән биш елдан артык вакыт узган булса;»;

түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пунктчасын өстәргә:

«$6^1$) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яисә банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турындагы гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителгәндә;»;

4 пунктның 3 пунктчасында:

дүртенче абзацта «3 пунктчада» сүзләрен «2 пунктчада» сүзләренә алмаштырырга»;

җиденче абзацта «6 пунктчада» сүзләрен «6, $6^1$ пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга»;

сигезенче абзацта «6 пунктчаның өченче абзацында» сүзләрен «$6^1$ пунктчасының өченче абзацында» сүзләренә алмаштырырга»;

түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пунктын өстәргә:

«$10^1$. Комиссия утырышы йомгаклары буенча, әлеге Тәртипнең 10 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 12 пунктын өстәргә:

«12. Әлеге Тәртипнең 10 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана һәм белешмә өчен Комитет рәисенә җибәрелә.».